Республика Татарстан
Руководитель Исполнительного комитета Чубуклинского сельского поселения Заинского муниципального района

ул. Молодежная, д. 229/В, с. Чубуклы,
Заинский район, 423534

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Чыбыклы авыл җирлегенең
башкарма комитеты
җитәкчесе

Яшьләр урамы, 229/В йорты,
Чыбыклы авылы, Зәй районы, 423534

Телефон, факс 3-68-01. Электронный адрес: Chub.zai@tatar.ru, сайт: www.chubuklinskoe.jimdo.com

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24 июля 2020г.**

**КАРАР**
**№ 14**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 маендагы 07 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 2020 елның 07 февралендәге 16 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 маендагы 7 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (2019 елның 10 декабрендәге 13 номерлы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә кертелгән үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбулада «Җирлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарәсе махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары, муниципаль районнарның җирле администрацияләре башлыклары һәм муниципаль районнар җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында Инструкцияне

раслау хакында» 2017 елның 06 июнендәге 97 номерлы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы боерыгы белән" сүзләрен «Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында Инструкцияне раслау хакында» 2020 елның 07 февралендәге 16 номерлы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.4 пунктында тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 07.02.2020 елның 07 февралендәге 16 номерлы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы боерыгы белән" (алга таба - Инструкция) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 12.02.2020);».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **И.Н. Гадершин**